| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.10.2025 г. Казань № 780/2025

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 28 февралендәге 45/2022 номерлы боерыгы белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда планлы контроль (күзәтчелек) чараларын үткәргәндә кулланыла торган тикшерү кәгазьләре (җаваплары тикшереп торылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яисә үтәлмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлекләре) рәвешләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 28 февралендәге 45/2022 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 6 сентябрендәге 660/2023 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда планлы контроль (күзәтчелек) чараларын үткәргәндә кулланыла торган тикшерү кәгазьләре (җаваплары тикшереп торылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яисә үтәлмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлекләре) рәвешләренә кушымтада бирелә торган үзгәрешләрне кертергә.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
28.02.2022 ел, №45/2022 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 28 февралендәге 45/2022 номерлы боерыгы белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда планлы контроль (күзәтчелек) чараларын үткәргәндә кулланыла торган тикшерү кәгазьләре (җаваплары тикшереп торылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яисә үтәлмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлекләре) рәвешләренә кертелә торган үзгәрешләр

4 нче кушымтаның «Татарстан Республикасы чикләрендә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүче табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү» дигән 3 нче бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «3. Татарстан Республикасы чикләрендә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүче табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.1. | Мәгълүмат ачу стандартларында каралган мәгълүмат оешманың «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында бастырыламы (мәгълүмат ачу факты һәм ысулы)? | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 31 маендагы 821 номерлы карары белән расланган Торбаүткәргечләр буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүче табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының (алга таба – 821 номерлы Стандартлар) 3 пунктындагы «а» пунктчасы | | | |
| 3.2. | Территорияләрендә табигый монополияләр субъектлары торбаүткәргечләр буенча газ транспортлау буенча җайга салынулы хезмәтләр күрсәтә торган Россия Федерациясе субъектларында таратыла торган рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат басылып чыгамы? | 821 номерлы Стандартларның 3 пунктындагы «б» пунктчасы, 4 пунктындагы беренче, өченче абзацы | | | |
| 3.3. | Табигый монополия субъектының рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру турында хәбәр итү чорлары сакланамы? | 821 номерлы Стандартларның 7 пункты | | | |
| 3.4. | Мәгълүмат ачу составы һәм тәртибе сакланамы? | 821 номерлы Стандартларның II бүлеге | | | |
| 3.5. | Эшчәнлекнең җайга салынулы төрләренең һәркайсы буенча һәм | 821 номерлы Стандартларның 9, 10 пункты | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | магистраль газүткәргечләрнең һәм (яки) газ бүлү челтәрләренең һәр системасы буенча мәгълүмат аерым басылып чыгамы? | | | | |
| 3.6. | Мәгълүмат ачу вакыты (ешлыгы) үтәләме? | 821 номерлы Стандартларның 4 пунктындагы 1 абзацы, 6 пунктындагы 1 абзацы, 8 пункты | | | |
| 3.7. | Җайга салынулы оешма товарларыннан һәм хезмәтләреннән файдаланучыларның язмача гаризалары нигезендә мәгълүмат ачу тәртибе үтәләме? | 821 номерлы Стандартларның 3 пунктының «в» пунктчасы | | | » |

6 нчы кушымтаның «Табигый монополияләр өлкәсендәге оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү» 4 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «4. Табигый монополияләр өлкәсендәге оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4.1. | Тимер юллар өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм мәгълүмат составына карата таләпләр үтәләме? | 147-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьяның 5 пункты, 8.1 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 28 маендагы 736 номерлы карары белән расланган Тимер юл ярдәмендә ташу өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 736 номерлы карары белән расланган Мәгълүмат ачу стандартлары) 2, 3, 4 пункты, 9 пунктының «а», «б», «е» пунктчалары, 10-13, 15, 16 пунктлары;<br>Федераль тарифлар хезмәтенең «Тимер юл ярдәмендә ташу өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу формаларын, чорларын һәм ешлыгын раслау турында» 2011 елның 19 апрелендәге 158-т номерлы боерыгына (алга таба – Федераль тарифлар хезмәтенең 158-т номерлы боерыгы) кушымта | | | |
| 4.2. | Транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда һәм эчке су юллары инфраструктурасын куллану буенча хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы табигый монополияләр | 147-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьяның 5 пункты, 8.1 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 30 маендагы 797 номерлы карары белән расланган Транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының (алга таба | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | субъектлары тарафыннан ачылырга тикшле мәгълүматны тапшыру тәртибе һәм бу мәгълүмат составына карата таләпләр үтәләме? | – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 797 номерлы карары белән расланган Мәгълүмат ачу стандартлары) 3 пункты, 4 пунктның икенче абзацы, 6 пункты, 9 пунктының «а», «б», «е» пунктчалары, 16, 17, 30 – 31, 35, 37, 38, 43 пунктлары;<br>Федераль тарифлар хезмәтенең «Транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда һәм эчке су юллары инфраструктурасын куллану буенча хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә эшчәнлек алып баручы табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу рәвешләрен, чорларын һәм ешлыгын раслау турында» 2011 елның 19 апрелендәге 159-т номерлы боерыгына (алга таба – Федераль тарифлар хезмәтенең 159-т номерлы боерыгы) 1, 2, 3 кушымталар | | | |
| 4.3. | Тимер юлларда ташу өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу чорлары һәм ешлыгы сакланамы? | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 736 номерлы карары белән расланган Мәгълүмат ачу стандартларының 3 пунктының беренче абзацы, 6 пунктының 1 абзацы, 7, 8, 11 пунктлары;<br>Федераль тарифлар хезмәтенең 158-т номерлы боерыгына кушымтаның 2, 3 пунктлары | | | |
| 4.4. | Транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда һәм эчке су юллары инфраструктурасын куллану буенча хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы табигый монополияләр субъектлары тарафыннан ачылырга тиешле мәгълүматны ачу чорлары һәм ешлыгы сакланамы? | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 797 номерлы карары белән расланган Мәгълүмат ачу стандартларының 4 пунктының 1 абзацы, 7, 11 пунктлары;<br>Федераль тарифлар хезмәтенең 159-т номерлы боерыгына 1, 3, 4 кушымталар | | | » |